РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВАРЯШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423979 РТ Муслюмовский район,с.Варяш-Баш, ул.Кооперативная, д 31а*
Vbash.Mus@tatar.ru тел.8(8-5556)3-07-20

---

**КАРАР № 8**

Вәрәшбаш авылы 07 апрель 2021 ел

**«Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.02.2017 ел, 4 нче номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Төп муниципаль актка үзгәрешләр кертә торган муниципаль акттагы хаталарны төзәтү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Вәрәшбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.02.2017 ел, 4 нче номерлы карары белән расланган « Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6.2 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.2. 2.8 пунктының соңгы абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.9 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

1.4 3.3 пунктының 2) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2) ведомствоара гарызнамәләр җибәрә:

салым органында исәпкә кую, салым, җыемнар, пеняләр һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар барлыгы (юклыгы) турында Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарама комитет җитәкчесе** **З.М.Маннапова**